**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 июлендәге 2548 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 июнендәге 2025 номерлы**
**«2026 елның 21 июлендә Казан шәһәрендә хач йөрешен**
**үткәрүдә булышлык итү турында»гы карарына**
**үзгәреш кертү хакында**

2026 елның 21 июлендә хач йөрешен үткәрү вакытында гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 10 июнендәге 2025 номерлы «2026 елның 21 июлендә Казан шәһәрендә хач йөрешен үткәрүдә булышлык итү турында»гы карарына, 1.1.2 пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«1.1.2. 2026 елның 21 июлендә 07.00 сәгатьтән 09.30 сәгатькә кадәр Большая Красная урамының автомобиль юлы буенча, 3 һәм 3А номерлы йортлар арасындагы юлны да кертеп, Япеев урамыннан Батурин урамына кадәрге участокта»;

1.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**